**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы КАРАРЫ

№ 2-11

2025 елның «15» октябреннән

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 6 сентябрендәге 36-296 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 3 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниипаль районы Советының 2023 елның 6 сентябрендәге 36-296 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2024 елның 27 мартындагы 43-335 номерлы, 2024 елның 23 октябрендәге 49-381 номерлы карарлары редакциясендә) расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 7 статьясындагы 2 бүлекнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) һөнәри белем дәрәҗәсенә: авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарындагы вазыйфалардан тыш, вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәүче төркемнәре өчен; авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарында вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәүче төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу.»;

1.2. Нигезләмәнең 7 статьясындагы 2 бүлекнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы кимендә бер ел яки белгечлек, юнәлеш буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы яисә кимендә бер ел әзерлек юнәлеше буенча эш стажы.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда

https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы — Е.А. Тарнавский